| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Петровско-Заводского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Петровский Завод<br>авыл җирлеге башкарма комитеты |
| --- | --- |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2024 ел, 30 январь | № 1 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 8370,20 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2023 елның 31 январендәге 1 нче номерлы карарын һәм «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 февралендәге 2а номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Нуртдинов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән үлгән кешенең күмү бурычын үз өстенә алган хатынына (иренә), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкилгә яисә башка затка җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4971,19 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1748,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1650,36 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2024 елның 30 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән үлгән кешенең хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яки законлы вәкиле булмаган яки җирләү мөмкин булмаган очракта, шулай ук эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң,өйдә, урамда яки башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка кешеләр булмаганда, җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Кәфенләү | 1568,46 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3402,73 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1748,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1650,36 |
| Барлыгы | 8370,20 |